**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге башлыгы карары**

**2021 елның 12 ноябре** **№ 5**

**«Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Кече Чура авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 23 ноябрenә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Кече Чура авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә.
   Гражданнар җыенын Кече Чура авылы, Мэктэп урамы, 2 йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. 2021 елның 23 ноябрenә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Кече Чура авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә.
   Гражданнар җыенын Кече Чура авылы, Мэктэп урамы, 2 йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

3. 2021 елның 23 ноябрenә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Югары Чураавыл җирлегенең Югары Чура авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә.
   Гражданнар җыенын Кече Чура авылы, Мэктэп урамы, 2 йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

4 Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары һәм шулай ук 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Кече Чура авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча

теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Кече Чура авылының Зеленая, Мәктәп, урамнарындагы юлларга вак таш җәю (вак таш сатып алу, ташу, җәю); проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтү үткәрү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Кече Чура авылыннын Мәктәп, урамында вак таш җәеп юлларда чокырларны ремонтлау (ямочный ремонт); проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Кече Чура авылында урамнарны яктырту өчен энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Кече Чура авылының Мәктәп урамына юл билгеләре сатып алу; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

-Кече Чура авылы зираты янындагы автомобиль юлын (переход) ремонтлау; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Кече Чура авылында Бур елгасы аша җәяүлеләр юлын ремонтлау; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Кече Чура авылы зиратын коймалау өчен материал сатып алу; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Кече Чура авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Кече Чура авылы урамнарында коры агачларны һәм куакларны кисеп ташлау, кисү һәм санитар эшкәртү; махсус техника яллау; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Кече Чура авылында видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру. килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Кече Чура авылының Зеленая урамында асфальт җәю һәм вак таш җәеп ремонтлау; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

« РИЗА КАРШЫ"»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Югары Чура авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Чура авыл җирлеге башлыгы: В. Н. Андреев